# КАРАР (РЕШЕНИЕ)

## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге составына керүче торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

28.03.2024 №1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 26 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына таянып 2024 елның 28 мартында узган гражданнар җыенында «Сез «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге составына керүче Югары Симет торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 27.10.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертүгә « 2024 нче елда Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге составына керүче Югары Симет торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 (биш йөз ) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге максатларда файдаланырга:

1)Югары Симет авылының Пионер һәм Мәктәп урамнарын тоташтыручы җәяүлеләр күперен ремонтлау һәм әйләнә-тирәсен төзекләндерү;

2)Югары Симет авылында гидрант урнаштыру дигән сорау буенча 2023 елның 27 октябрендә узган халык җыены 2 карарында күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге эш төрләренә үзгәртергә:

1) Югары Симет авылының Пионер һәм Мәктәп урамнарын тоташтыручы җәяүлеләр күперен ремонтлау һәм әйләнә-тирәсен төзекләндерү;

2) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (Югары Симет авылында гидрант урнаштыру)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 279 кеше кертелгән, җыенда һәм тавыш бирүдә катнашучылар саны 141 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 141 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге составына керүче Югары Симет торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «Сез «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге составына керүче Югары Симет торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 27.10.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертүгә, 27.10.2023 елгы 2 нче карарында күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге эш төрләренә үзгәртүгә:

1) Югары Симет авылының Пионер һәм Мәктәп урамнарын тоташтыручы җәяүлеләр күперен ремонтлау һәм әйләнә-тирәсен төзекләндерү;

2) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (Югары Симет авылында гидрант урнаштыру) ризамы», карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/simet адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Югары Симет авыл
җирлеге башлыгы

И.Р.Әхмәдуллин